# Безнең күктәге Атабыз

**1**

Безнең күктәге Атабыз
Минем догамны, Син ишет.
Данлы, данлы Синең эшләр
Мәңге Исемең булсын изге. /2

**2**

Бар белүче Син, көдрәтле
Барсы калтырый Синең алдында.
Бар күрүче һәм бар җирдә
Синең патшалыгың килсен! /2

**3**

Акыл иясе- Син Аллам
Бәхеттә минем уйларым.
Бар дөнья давылларында
Синең ихтиярың булсын./2

**4**

Безнең мәрхәмәтле Алла
Барысына тормыш бирәсең.
Һәм Сиңа барсы үтенә
Бүген икмәгебезне бир./2

**5**

Син мәрхәмәтле һәм гадел,
Безнең гөнахларны кичер.
Без дә онытып дошменнарга
Барысын кичергән кебек./2

**6**

Синсез кем гөнаһсыз булган,
Вәсвәсәгә безне кертмә.
Безне көдрәтле Аллабыз,
Явыз көчләрдән, Син, сакла./2

**7**

Синең гаҗеп бар эшләрең
Синең инде патшалыгың.
Сиңа мәңге мактау һәм дан
Мәңге мәңгегә. Амин! /2

## Гүзәл дөнья

**1**

Гүзәл дөнья көтә безне күктә,
Анда эшләр кайгылар бетәр
Газаплардан онтылып ул илгә
Мин барам мәңгелек шатлыкка.

***<u>Кушымта</u>:***

**И гхзәл як, и гүзәл як**
**Күңелем Сиңа омтыла.**
**И гүзәл як, и гүзәл як,**
**Анда безне Аллабыз көтә.**

**2**

И гүзәл як, дан җырлыйлар
Фәрештәләр анда бергәләп.
Гайсәге Алар дан күтәрәләр,
Аллилуйя әйтеп җырлыйлар.

**3**

И гзәл як, күк яктысында
Без күрербез Гайсәнең данын.
Гүзәл далаларда, бакчаларда
Мәңге бәхетле мин булырмын.

**4**

Гүзәл якка тиздән без килербез
Коткаручыбызны күрербез.
Хәсрәтләнгән йөрәк анда тынар
Мәңге булыр шатлык һәм бәхет.

## Гаҗәп бу көн

**1**

Гаҗәп бу көн, гаҗәп вакыт,
Коткаручым беренче тапкыр.
Минем рухыма, васыять бирде.

***Кушымта:***

**Гаҗеп бу көн /2**
**Кайчан Ходай мине кичерде.**
**Шуннан бирле Ул минем белән,**
**Йөртә мине Үз кулы белән.**
**Гаҗәп бу көн/2**
**Кайчан Ходай мине кичерде.**

**2**

Гаҗәп бу көн, кайчан Гайсә,
Күз яшемне туккәндә тапты.
Ул минеке мин Аныкы,
Ходай мине Үзе тапты.

**3**

Гаҗәп бу көн, кайчан сузды
Кулын, күзләрем ачылды.
Һәм Мәсихне күреп рухым
Мәхияләр җырлап йөрде.

**4**

Гаҗәп бу көн, рухым белән
Шатлыклы тормыш башладым.
Кайчан бәхет һәм тынычлык
Коткаручым миңа бирде.

**5**

Гаҗәп бу көн, мин ышандым
Йөрәгем белән яратуына.
Һәм мин юылдым төшкән
Хачтан Аның каны белән.

## Мактау Сиңа безнең Ходай

Мактау Сиңа, безнең Ходай.
Мактау Сиңа, Изге Алла,
Мактау Сиңа Синең Улыңа
Гайсә Мәсихкә.
Көчсез Сиңа әйтер: “көчле мин”,
Ярлы әйтер: “ бай бит мин”!
Безнең Алла бер генә, кешеләргә,
Мактау!

## Давыллы диңгез өстеннен

**1**

Давыллы диңгез өстеннән
Еракта һавада,
Дәһшәтле җилгә каршы
Очтылар торналар.

***<u>Кушымта:</u>***

**Тик берсе читтә онытылган,**
**Сынган канатлысы**
**Тирән кайгыдан әрнеп,**
**Як- якка каранды.**

**2**

Очарга бик теләсә дә,
Диңгездән биектә,
Ләкин гел аска очты
Диңгез упкынына.

***<u>Кушымта:</u>***

**Һәм үлемен ул шунда**
**Очратырмын диде,**
**Кинәт, бер көймә күрде**
**Дулкыннар өстендә.**

**3**

Яраласалар сине
Тормыш давылында,
Дустым, курыкма
Кара ышанып югары.

***<u>Кушымта:</u>***

**Тыңгысыз диңгез өстендә,**
**Дөнья җилләрендә**
**Кайгы газаптан кот҆ә,**
**Гайсә Коткаручы.**

## Күпме еллар үтте

**1**
Күпме еллар үтте, сулар акты,
Гайсә үлеп терелгән көннән.
Ләкин гөнаһ артканнан артты,
Китмәде ул каһәрле җирдән.
**2**
Юккамыни Ата Улын җибәргән,
Корбан итеп безнең гөнаһлар өчен?
Юккамыни Гайсә гомерен биргән
Кызганмаган яшлеген, бар көчен?
**3**
Әй, дусларым булмаган юкка корбан,
Кимсетүләр, күз яшләре, авыртулар.
Юкка коелмаган бу Изге Кан,
Пакъләнгәннар безнең гөнаһлар.
**4**
Әй, халыклар, йокламагыз, уяныгыз!
Антка килегез Алла каршында.
Чын йөрәктән Гайсәне сез чакырыгыз.
Гөнаһларның кичерер Ул барсын да.
**5**
Бу дөньяда без кунакта гына,
Чәчкә гөмере- безнең бу гөмер,
Дустым, ышан , син, шуңа гына
Мәңгелектә Гайсә белән урының булыр!

## Мин телим аңларга.

**1**

Мин телим аңларга мәхәббәт сүзен,
әйтер өчен һәркемгә ярату сүзен.
Сөю җыры агылсын күңел күккә ашкынсын,
Данлагыз, сез, данлагыз, сез бөек Алланы,
Данлагыз, сез, данлагыз, сез, бөек Гайсәне.

**2**

Алла бит сөю булып бу җирге килде.
Гөмернең һәр көнен Ул безгә бирде.
Яратып яшәргә, мәхәббәт чәчәргә
Данлагыз, сез, данлагыз, сез, бөек Алланы,
Данлагыз, сез, данлагыз, сез бөек Гайсәне.

**3**

Ул безне ярата чын сөю белән
Шуңа Ул безнең өчен гөмерен биргән
Аллам Син ! Мәхәббәт
Гайсәм Син ! Мәрхәмәт
Данлагыз, сез, данлагыз, сез  Алла сөюен,
Данлагыз, сез, данлагыз, сез Алла сөюен.

## Минем газиз туган җирем

**1**

Минем газиз туган җирем
И кадерле татар илем,
Синдә гармуның моңнары,
Синдә урманнар шаулавы,
Чишмәләрнең чылтыравы
Сандугачларның сайравы,
Тәпи атлап киткән җирем
Ата- бабам үскән илем. /2

**2**

Ходай Улы, туган җирдән
Булсаң да син бик еракта.
Бөек мәхәббәте белән
Ул бит сине дә ярата.
Синең халкың да газаптан
Котылсын дип Гайсә - Мәсих.
Канын коеп корбан булды
Синең өчен җанын бирде. /2

**3**

Сезгә дәшәм, якташларым,
Гайсә аша кардәшләрем
Бердәм булып догабызга
Ярдәм итик халкыбызга.
Үрнәк булып кешеләргә
Дөреслекне аңлатырга
Ярдәмнәрен бирер Ходай
Изге булыр Рухыбыз да. /2

## Гайсәдә генә...

**1**

Гайсәдә генә мин бәхетле һәрчак,
Гайсәдә генә мин ял итәм эштән.
Бөтен серемне мин Аңа сөйлим,
Иң якын дустымны таптым Аңардан.

***<u>Кушымта:</u>***

**Гаөсәнең иптәше булу- зур бәхет,**
**Тел белән моны һич булмый аңлатып.**
**Бөтен серемне мин Аңа сөйлим**
**Иң якын дустымны таптым Гайсәдә**

**2**

Мәңге яратырмын мин Ул дустымны,
Дустым коткарды мине үз канында.
Күрсәтте хачта үзенең мәхәббәтен,
Иң якын дустымны таптым Гайсәдә.

**3**

Мәңгелек дуслык кулын сузып миңа
Яшьлектән бирле алып бара мине
Ул яши торган илгә мин барам
Җаным мәңгелек шатланыр Анда.

## Һәркем сусаучы- кил монда һәм эч.

**1**

Һәркем сусаучы- кил монда һәм эч,
Тере сулар аккан чишмәдән,
Аллага ышансаң Аны яратсан,
Бөтен тормышыңны Ул яңартыр.

***Кушымта:***

**Аллилуйя! Дан Сиңа, мактау, /3**
**Аллилуйя! Сиңа Гайсә мактау,**

**2**

Әгәр талчыксан, арысаң барганда,
Ул ярдәм итәр тормыш юлында.
Йөгеңне алыр, яңа көч бирер,
Бар кайңында ярдәмче Ул булыр.

**3**

Аннан ут сора һәм бирер сиңа,
Шатланып басып алга барырсың.
Ышан гел Аңа, таян гел Аңа,
Һәм бөтен тормышыңны ул яратыр.

**4**

Аңа бирелгән Ул юлны үтте
Артыннан, хәзер, син бар юлыннан.
Һәркемне өнди; Патшалык- вәгъдә
Нык тор юлында, эзеннән Аның син бар.

## Тик Аллада гына

**1**

Тик Аллада гына җаның табар, тынычлык, бәхет
Әгәр Ходай артыннан барсаң, Аның артыннан.
Ул сине күптәннән чакыра,
Коткарып бәхет бирәсе килә.
Ә, син ,кил. /2

**2**

Бозык, гөнаһлы дөньяны ташла, ул явызлык тулы,
Юк мәхәббәт һәм анда тулы ыгы-зыгы
Әй, син Мәсихкә килергә ашык
Бәхет һәм тынычлык табарга
Аның янында. /2

**3**

Ишетәсеңме, Ул сине чакыра син ашык
Күз яшьләре ничек ага гөнаһлар өчен.
Тик нигә син ашыкмыйсың, дустым,
Алла балалары арасында
Булырга, син, ашык /2

**4**

Ул сине явызлардан саклар һәм хәсрәттән
Шатлык һәм кайгыңны уртаклашыр Ата кебек.
Кайгыда сине ныгытып торыр.
Әгәр Аңардан син сорасаң
Һәр көнне. /2

## Бөек Алла

**1**

Бөек Алла! Мин дөньяга караганда,
Син яраткан барлык нәрсәләргә.
Син яктылык биргән табигаткә
Үз мәхәббәтеңне таратасың.

***Кушымта:***

**Шул чак җырлый минем**
**Рухым Ходай.**
**Тик Син бөек. /2**

**2**

Мин һавага йолдызларга караганда,
Кайда шундый тыныч һәм яктылык
Кайда кояш та айда мәңгелек.
Дингездә кораблар йөзгән кебек.

**3**

Болытлардан күкрәү яңгыраганда,
Караңгыда яшен яшнәгәндә,
Җир өстендә яңгырлар яуганда,
Йәйгөр минем күңелне яктырта.

**4**

Мин Алланың изге һәм могҗизалары,
Эшләре турында укыганда,
Ничек Ул кешене яраткан да
Һәм коткарган аны гөнаһлардан.

## Бөек Аллам минем

**1**
Бөек Аллам минем
Җаным Сине җырлый.
Даның белән Синең
Күк йөзе, җир гөрли.

***Кушымта*:**
**Сиңа, Аллам минем,**
**Мәңге рәхмәт укыйм.**
**Данлый Сине кошлар,**
**Гөлләр һәм чәчәкләр.**

**2**
Килик бергә, дуслар,
Аллабыз каршына.
Саф йөрәкләр белән
Аңа без дан җырлыйк.

**3**
Бу галәмдә башка
Аңа тиңнет бит юк.
Безне Ул яраткан,
Мәңге тормыш биргән.

## Изге Язма

**1**

Изге Язма ул бер генә.
Безнең тормышны үзгәртә
Анда без күрәбез, ничек
Коткаручы газап чиккән

**<u>Кушымта</u>:**

**Гүзәл якты, сирпи аннан**
**Тормыш карангылыгында,**
**Алла сүзе бу дөньяда,**
**Арганнарга тормыш бирә.**

**2**

Изге Язма ул бер генә
Тормыш бар дип хәбәр бирә
Атабыз мәхәббәтендә
Галгофа һач газабында.

**3**

Изге Язма ул бер генә
Үлем җиңелгән дип әйтә;
Гайсә Үзен кызганмаган,
Безнең өчен җанын биргән.

**4**

Кем Язманы яратса
Кабер, куркуын ул белмәс.
Безгә бит ул өмет бирә,
Күктә шатлык көтә дия.

## Алла сулары

**1**

Килдем әле Синең янга
Башны иеп каршыңа
Гайсә кабул ит, Син, мине,
Булыйм әле яныңда.

***Кушымта:***

**Челтерәп агадыр**
**Чишмәләрә Ходайның**
**Мин дә килеп суын эчтем**
**Басылды сусауларым.**

**2**

Килгәнне кумый Ул Гайсә,
“ Көтәм”- дип хәбәр бирә.
Дус кына түгел, баласы
Диеп Ул кабул итә.

***Кушымта:***

**Ага бит сулары**
**Ходайның тәхетеннән.**
**Шушы суны эчкен кеше**
**Мәңге сусамас бүтән.**

**3**

Әйдә килеп татыгыз, сез,
Нинди ямьле бу тормыш.

Бу тормышны Гайсә бирә
Аннан калмаска тырыш.

***<u>Кушымта:</u>***
**Сузадыр кулларын**
**Басадыр дәваларын**
**Тормыш бозган елларның**
**Биршдер яңаларын.**

## Шатлап кайгырма

**1**
Кемнәр боегып яшиләр Аның янына килегез.
Һәркемне яратып көте Ул, сүрелмәсен өметегез.
***<u>Кушымта:</u>***
**Шатлан, төшенмә, кайгырма, ә балкы**
**Кылучыга рәмәт ers/ Данла син рухта**
**Рух һәм чынлыкта рәхмәтле бул Атага.**

**2**
Аңа бер адым ясагыз, сезгә Ул кулын сузыр
Күктә һич мактау тукталмас, кабынсын йөрәктә утлар.
***<u>Кушымта:</u>***

**3**
Аңа “ Аллилуйя”! – диген, Кылучыга дан жырла
Ул безгә xsy тормыш бирә һәм күке өнди яшәргә.
***<u>Кушымта:</u>***

## Кемдер жырлый

**1**
Кемдер жырлый, күңелсез кичне үткәреп
Кемдер жырлый дөнья халкын күңел ачып,
Ә мин жырлыйм, Алламны данларга

Җырлый күнел, җырлый җаным. /2

**2**

Күңелдә минем ярату цыры яңгрый
Аллам минем белән булгач, күңел җырлый.
Шул якты моң белән Аллага дан җырлыйм,
Җырлый күнел, җырлый җаным.

**3**

Телимен мин. Алла сүсендә торырга,
Дога кылып ышанырга өметем бар.
Кайгы килсә- Алланы данларга,
Җырлый күнел, җырлый җаным.

## Син – Изге Аллам

**1**

Син- минем Аллам,
Мин Сиңа ашкынам
Тик Синдә тынычлык табам.

***Кушымта:***

**Тынычлык табармын күкрәгендә,**
**Йөрәгем минем тынычланыр.**

**2**

Мин беләм, Синдә- мәңгелек шатлык
Үзгәрми торган мәхәббәт.

**3**

Инде беркем дә шушы шатлыкны
Йөрәгемнән кире алмас.

**4**

Гөмернең соңгы сәгате җитсә,
Мин беләм, каршы алырсың.

**5**

Син- Бөек Аллм,
Мин Сиңа талпынам,
Тик Синдә куаныч табам.

## Күңелем тулы мактау

**1**

Күңелем тулы мактау җыры минем
Телләремнән аксын җыр булып.
Бөеклегәң мактап җырлар идем
Син, Раббыма, сайрар кош булып.

**2**

Ышанычым , минем өметем
Синдә минем төпле урыным
Сине мактап нинди җырлар җырлыйм,
Сүзем саран, тирән уйларым.

**3**

Күңелемне тутыр тирән моң белән
Һәр минутта Сиңа сокланам.
Кемгә карап кемгә ышаныйм соң,
Чагыштырыйм Сине кем белән?

**4**

Бөтен дөнья тулган нурың белән,

Синең белән дөнья яктыра.
Шул нурыңда яктырт мине Ходай
Шул нурыңда күңелем яктыра.

## Котылу кыясе

**1**

Йөрәгем елаганда, дога кылганда,
Яшьтән күзләрем юеш чакта, ишет мине!
Әй, Атам, киптер күзләремне.
Йөрәгем елаганда, белгерт ишеткәнеңне
Кайда гына йөресәм дә,
Юлымда сакла мине.

***Кушымта:***

**Алып бар мине кыяга,**
**Кыяга илт мине,**
**Котылу кыясына**
**Алып бар мине кыяга,**
**Котылу кыясына.**

## Беләм мин дөньяда

**1**

Беләм мин дөньяда
Тынычлык таба алмыйм.
Бик күпләр эзләде тик тапмады.
Син җаныма керәсең, тынычлык бирәсең,
Әй, Ходай, кабул ит догамны.

***Кушымта:***

**Мәңгелек мәхәббәтең белән Син мине яраттың**
**Данлыйм Сине, Кылучым Аллам,**
**Урын көйле Син йөрәгем түрендә**
**Арындыр сагыштан, моңнан, ачудан.**

**2**

Монда мин ялгызым.
Тик Син калдырмыйсың мине
Һәм шатлык белән йөрәгемне тутырасың,
Син булышчым, көчем, минем өметем.

**3**

Күкнең көчләрен куйдым сакларга
Йөзем мин куркусыз.
Көймәм- Син минем
Соңыннан азакта, күктә яктыда
Бәхетле илдә каршыларсың мине.

## Аллам, сакла мине

**1**
Аллам, сакла мине, Аллам, сакла,
Изге китап белән яшәт мине.
Бөек Сүзен белән яшәү бир, Син миңа
Аллам, сакла мине, Аллам, сакла!

**2**
Акыл бир, Син мина, Изге Аллам,
Мәхәббәт, ышаныч һәм дә өмет,
Мәңгелеккә Үзең алып бар, Син мине,
Аллам, сакла мине, Аллам, сакла!

**3**
Кайда булсам да мин, Изге Аллам,
Синең сүзең белән алга барам.
Дошман арттан килеп куркытырга торса,
Аллам, сакла мине, Аллам, сакла!

**4**
Гөнаһ якын булса, Изге Аллам,
Ярдәм һәм көч көтәм, минем Аллам.
Яшәргә мин телим һәрчак Синең белән
Аллам, сакла мине, Аллам, сакла.

## Тезләнеп баш иям

**1**

Тезләнеп баш иям, Аллам мине ишет,
Рәхмәтемне минем һәм кайгыларымны.
Тезләнеп баш иям һәм шул чак ишетәм
Йөрәгем тибешен, Алланың тавышың.

**2**

Сокланып мин карыйм; күк йөзе нинди саф,
Алланың янында мәңгелек яктылык.
Йөрәгем җылына шул яктылык белән,
Көчем тагын арта Алла Сүзе белән.

**3**

Тезләнеп баш иям, Аллам мине гафу ит,
Ялгышуларымны һәм гөнаһларымны.
Шул чакта мин аңлыйм; Алла ул- Изге сафлык
Караңгы юлларда Ул бирә яктылык.

**4**

Мин һәр чак баш иям, бөек Аллам каршында,
Йөрәгемне Аңа ышанып тапшырам.
Шул вакыт күңелем Алла Сүзен кабатлый:
“ Мин сине яратам, кил Минем каршыма”!

## Без үрнәк алабыз Синнен Гайсә

**1**

Без үрнәк алабыз, Синнән, Гайсә,
Без үрнәк алабыз Синнән,
Без Сине яратабыз,
Без үрнәк алабыз Синнән.

**2**

Син безгә юлны күрсәт, Гайсә,
Син безгә юлны күрсәт.
Без Сине яратабыз,
Син безгә юлны күрсәт.

**3**

Син үрнәк булып тор безгә, Гайсә
Син үрнәк булып тор безгә
Без Сине яратабыз,
Син үрнәк булып тор безгә.

## Ул килде коткарырга

**1**

Юлда югалмасын дип Ул килде коткарырга
чын хакыйккәтле кеше Ул килде коткарырга
Самарияле яктылыкны тапты тик Гайсәдә
Сусаган Ул кеше кебек, эчергән Алла сыман.

**2**

Суы ярсу, ерак яры, суда көймәдә.
Арыган Гайсә йоклый анда Давылны баса Алла.
Дусты үлгәч яшен койган, яшереп тормыйча
Елаган кеше сыман, терелткән Алла булып.

**3**

Аңа итмәүчеләр иман, белмиләр шуны
Гайсә- Алла Улы, Мәсих Коткаручы.
Кеше генә дип танучылар, нык ялгышылар.
Пәйгәмбәр дип беләләр, уйламылар Алла диеп.

**4**

Бар кешедән зур булса да, Ул абзарда туган
Килгән Ул кеше булып, Алла булып күтәрелгән.
Юлда югалмасын дип Ул килде коткарырга,
Чын хакыйккәтле кеше Ул, хакыйкәт- Алла Ул.

## Кичер мине Аллам

**1**

Кичер мине Аллам, Сиңа соң килдем,
Карангылыкта мин адашып йөрдем
Синең мине сөюүеңне белмәдем,
Гөнаһларым аша сине күрмәдем.

**2**

Хәзер Синең алда тезләнеп торам,
Кабул ит, Син, мине, кичер, Син, Аллам,
Йөрәгемә кереп яшә, Син, минем
Минем аша сибелсен Нурың Синең

**3**

Рәхмәт Сиңа, Аллам, мине Син таптың,
Изге Сүзен белән мине юяттын.
Минем гөнаһларымны Син кичердең
Мәңгелек тормышка мине китердең.

## Рәхмәт Сиңа яшәү бүләк иткән

**1**

Рәхмәт Сиңа яшәү бүләк иткән,
Мәрхәмәтле Изге Аллага,
Мөхәббәте һәм шәфъкәте белән
Мине сөеп сайлап алганга.

**2**

Бурычлымын Синең алда Аллам
Мәңге аны кайтара алмам.
Тирән сөю һәм ышаныч белән
Инанамын тик Сиңа, Аллам.

**3**

Яратырга телим һәр кемне мин,
Мәхәббәтем әммә җитми шул
Кичерергә яратырга кирәк,
Тормышымда миңа терәк бул.

**4**

Сакла мине, Аллам, мин көчсезне

Синнен башка гонаһ колы мин
Йөрәгемә кереп үзең яшә,
Коткаручым минем бары Син!

## Ышанам , ышанам

**1**
Гөнаһтан коткарды, Аллага китерде
Алла Улына мин ышанам
Тынычлык Ул бирә, Аллага алып бара
Гайсә Мәсихкә мин ышанам .

***Кушымта:***
**Ышанам, ышанам,**
**Чын йөрәктән Аңа ышанам**
**Ышанам, ышанам**
**Алла Улына мин ышанам**

**2**
Мине ул ярата, шуңа мин сөенәм,
Йөрәктән ышанам Аллага!
Гел мине Ул саклый, Ходаем бик көчле,
Гайсә Мәсихкә мин ышанам

**3**
Бәхетле мин дуслар, ышанам Аллага,

Чын йөрәктән Аңа ышанам
Мәңге мин мактарга Тәңремне телимен,
Гайсә Мәсихкә мин ышанам

**Мин Ибраһимның оныгы**

**1**
Дустым, кара як- ягыңа Син торган тирә- ягыңа
Көнчыгыш- көнбатыш. Бу җирләр бар да Сиңа.
Иман орлыгың Синең яр буендагы ком чаклы,
Арттырырмын Мин- диде Ибраһимга Аллаһы.
***Кушымта:***
**Мин Ибраһимның оныгы Ходай изгелеге белән,**
**Мин Ибраһимның оныгы утта чыныктырган иман**
**Гайсә бирде миңа өмет, ә мин Анарга ышанам**
**Ул Ибраһимнан элек булган, һәм мине дә Ул булдырган**.

**2**
“ Бәхиллимен Мин сине”- диде, “торган елларыңны”,
Ышан, син, Миңа, күрсәт иманыңны.
Синнән туган нәселне бәхиллимен Мин сине!

**3**
Алла әйткән сүзләргә Ибраһим ышанды
Шулай ул бик күпләрнең җирдәге Атасы булды.

Безнең күктәге Атабыз, юкны да Ул бар итә,
Чын күңелдән ышансаң , үлгәннән дә терелтә.

## Бу көнне

Бу көнне /2
Алла биргән /2
Сөенечкә, сөенечкә,
Һәм бәхеткә, һәм бәхеткә.

Бу көнне Алла бирген
Сөенечкәһәм бәхеткә.
Бу көнне , бу көнне
Алла биргән.

## Һәркем бу дөньяда

**1**

Һәркем бу дөньяда йөри үз юлы белән,
Һәркем үзенә эзли яхшылык
Кемдер эзли байлык, үз даның кемдер эзли,
Тик тормыш бирүчене эзләүче юк

***Кушымта:***

**Атам! Аларны кичер /2**
**Чөнки, нәрсә**
**Эшләгәннәрен белмиләр.**

**2**

Гайсәнең бу догасы галгофа һачында

Бүген дә һәр бер кеше өчен янгырый
Көтә Коткаручы Изге каны ага
Кайнар яшьләре ага күзеннән.

**3**

Үзен җезалаучылар өчен Ул дога кылган,
Һәркем өчен дә Аңа юл ачык.
Меңнәрче юллар калсын сайла тик берсен генә,
Сиңа тормыш бирүчене сайла.

**4**

Синең җаның, дустым, Алла өчен бик кыйммәт,
Шуның өчен шундый зур бәя бирелгән.
Соңга калма, ашык җирдә соңгы вакыт,
Алланың мәһәббәтен кире какма.

## Дан җырлыймын

**1**

Бөек Аллам, Гайсәм, Изге рухым,
Исемеңне Синең зурлыймын
Рәхмәт әйтеп Сиңа барсы өчен
Сиңа мәңгелек дан җырлыймын.

И сөекле, и кадерле Аллам,
Рәхмәт Стңа барлыгың өчен
Синең генә бар җиһанга җитә

Мәхәббәтең шәфькәтен көчен

**2**

Син- гүзәллек , Син- сөюнең Үзе,
Күңелләргә шатлык бирүче,
Җаныбызга тынгы, йөрәкләргә
Сүнмәс бер нур булып керүче.

Синең белән миңа шундый рәхәт,
Һәрчак тоям мәхәббәтеңне.
Авыр чакта Син ярдәмче миңа
Кызганмыйсың мәрхәмәтеңне.

**3**

Кыенлыклар куркынычлар килсә
Сыенам мин Синең куенга,
Һәм килгәндә шатлык сөенечләр
Син буласың минем уемда.

И шәфкәтле,изгелекле Атам,
Син Яклаучым да , Саклаучым да,
Бердән- берем, таянычым минем
Син булмасаң, нишләр идем мин?

## Ач йөрәгеңне

**1**

Дөнья нәфрәт белән тулган,
Һәм йөрәгең дә синең
Тик Аллабыз, бөек Ата
Мәхәббәтен аңлата.

***<u>Кушымта:</u>***

**Ул бит- Улым Минем,**
**Яктылыгым Минем,**
**Сүзем Минем Гайсә.**

**2**

Алла дөньяны яратып
Улын биргән үзенең,
Тели Ата, син алсын дип
Яшәү- мәхәббәтен Аны.

**3**

Аңа син ач йөрәгеңне,
Һәм кабул ит керергә.
Пакъләндерсен ул сине,
Йөрәгендә гел булсын Гайсә.

## Тыңлагыз кешеләр

**1**

Тыңлагыз кешеләр, бу Изге Хәбәрне!
Тыңлагыз, сез, Алла турында!
Хәбәрләрнең үлемсезе булып.
Ул күчкән буыннан буынга.

**2**

Күп гасырлар аша килеп җиткән
Шушы хәбәр безнең көннергә.
Бөек Аллам! Синең изге исемең
Кабатлана төрле телләрдә.

**3**
Мактау Сиңа, Раббым! Һәм дан Сиңа!
Гайсә булып җиргә килгәнсең
Безнең гөнаһларны Син Үзеңе алып,
Газапланып һачта үлгәнсең.

**4**
Үлгәнсең дә, кабат терелгәнсең,
Коткарырга безнең җаннарны.
Алып барыр өчен мәңгелек тормышка
Раббым Сиңа инанганнарны.

**5**
Син- гаделлек! Син- мәңгелек яшәү!
Рәхмәт Сиңа бөек Аллабыз.
Синең үлемсезлегең алдында
Тезләнеп без сәждә кылабыз.

**Әй догалар**

**1**
Әй, догалар, әй догвлар,
Аларны Алла бирген
Әче тормыш юлларында,
Бу догалар көч бирген.
Караңгы төн булганда,
Мин догада торганда
Алла белән күңелем сөйләшә:
-Әй, Аллам, мине ишет!
Ташлама фатиханнан.
Коткар, гафу ит
Гонаһлардан.

**2**
Әй, Аллам, җиңел тормышыңны

Мин Сиңнен сорамыйм.
Авырлыклар һәм кайгылар,
Булса да тормыш юлымда
Бары тик шуны сорыйм:
Һәрвакыт бул минем янымда
Кайда гына язмыш йөртсә дә,
Синең йомшак кулларың
Назлап иркәләсен,
Тормышымда,
Мине җитәкләсен.

**3**

Әй догалар, әй догалар,
Рәхмәт яусыннар сезгә
Алла сүзе мәңге көчле,
Дәрт бирә тормышыма.
Әй, Аллам, рәмәт Сиңа,
Көч бирдең күңелемә
Авыр булганда тормыш юлы
Әл дә Син бар дөньяда,
Күңелне коткаручы,
Безгә мәңгелек гомер бирүче.

## Рәхмәт җырлыйм

**1**

Мин рәхмәтле Изге Ходаема
Нинди сүзләр табып аңлатыйм.
Әй, Ходаем, Тәңрем Атам минем
Сузды миңа кулын юлымда.

**2**

Сиңа бүген минем мактау җырым,
Сиңа аксын данлау сүзләрем.
Миңа булган изге мәхәббәтең
Юлларымда яктыртуың өчен.

**3**

Син бит миңа изге юлны ачтың:

" Кем диясең, бул гел янымда.
Мәңгелектә урын миңа әзер,
Тугры булсаң Минем сүземә".

**<u>Кушымта</u>**

Данлыйм Сине, Гайсә минем өчен
Изге каның Синең коелган.
Күкләрдәге Яшәү китабына
Исемем минем язып куелган.

**5**

Мин мактыймын Сине, Данлы Гайсә,
Бар халыкка ирек, бирәсең.
Изгелеген санамыйча һәркөн
Мәрхәмәтең белән киләсең.

## Галгофа юлы

**1**

Галгофа юлы ерак-
Битеннән кан ага
Күпме әрнү Аның күзендә.
Гайсә минем өчен җәзаны,
Каһәрне, үлемне алган Ул Үзенә.

***<u>Кушымта:</u>***

**Бекайчан онытмам,**
**Мин андагы һачны,**
**Җир белән күк арасында Ул**
**Үз үлеме белән**
**Атага юл ачты,**

**Сатып алды үз каны белән.**

**2**

Әй, ишет син, кеше,
Бу җырымны минем.
Ашыкмыйсың, дустым, ник килмисең?
Ни белән түлисең Алланың бүләгенә
Коелган канына ни бирәсең?

***Кушымта:***

**Бу бөек зур җирне,**
**Яктылык, шатлыкны.**
**Синең өчен Алла тудырган.**
**Гайсә дәшә, әй, кил,**
**Аны узып китмә.**
**Тынычлык, бәхетеңтабырсың.**

**3**

Аңлатып бир, Ходай,
Искиткеч мәхәббәтнең
Безгә күктән ничек иңгәнен.
өәм тынычлык белән заман алга барырмын
кайгы хәсрәтне җиңеп яшәрмен.

## Алла белән яшәп

**1**

Алла белән яшәп
Аның белән үлү-
Бәхетлерәк язмыш
Булу мөмкинме?

Мондый язмыш өчен
Көрәшергә кирәк.
Һәм данларга кирәк
Һәрбер көнне.

**2**

Алла белән яшәү-

Гөнаһларны җиңү.
Бөгемә, син, авыр
Тормышыңа.

Авыр йөрәгеңне, син,
Тик Гайсәгә тапшыр.
Зарланмыйча ачы
Язмышыңа

**3**

Гаөсә белән яшәп,
Аның белән үлү.
Вәгьдә итә сиңа
Аның рәхмәтен.

Барлык газаплардан
Ул коткарыр сине.
Һәм татырсың күктә
Яшәү рәхәтен.

## Нинди шатлык

**1**

Нинди шатлык, нинди бәхет
Ходай мине коткарды!
Күкләрдәгн изге илдә урын әзерләде-
Данлыйм Сине, Син үлдең минем өчен һачта
Данлыйм Сине, данлыйм Сине, Аллам,
Данлыйм Сине.Амин.

**2**

Туганнарыма бирелде шатлык бу дөньяда,
Гайсә биргән яктылыкны күрәбез монда да.
Данлыйм Сине, Син үлдең минем өчен һачта

Данлыйм Сине, данлыйм Сине, Аллам,
Далыйм Сине.Амин.

**3**

Изге илдә көннәр булмый, кояш кирәкми
Ходайга рәмәтләр яңгырый, күз яшьләр дә булмый
Данлыйм Сине, Син үлдең минем өчен һәчта
Данлыйм Сине, данлыйм Сине, Аллам,
Данлыйм Сине. Амин

## Җырлыйм зәңгәр күккә

**1**

Җырлый, җырлый зәңгәр күккә
Кыюлык белән карыйм.
Җаным тынды, шикләр бетте,
Рухым данлый Мәсихне.

**2**

Аның Каны мине азат итте,
Яктылыкка мине чыгарды
Гаҗәп мәхәббәтен ачты,
Таштырып Рухын сипте.

**3**

Тормышта давыллар очратсам,
Гайсәне ярдәмгә чакырам.
Ышанам, Ул миңа елмаеп,
Яралы кулларын сузачак.

## Эзләгез Алла патшалыгын

**1**

Эзләгез Алла патшалыгын тәүдә
Һәм Аның хакыйккатен.
Бар калганы сезгә бирелер,
Аллилуйя. /2

**2**
Сорагыз һәм бирелер сезгә,
Эзләгез һәм табарсыз.
Кагыгыз, һәм сезгә ачылар,
Аллилуйя. /2

**3**
Күк патшалыгы ризык су түгел,
Һәм тынычлык.
Һәм сөелер Изге Рухта
Аллилуйя. /2

## Табигать тә мактый Алланы

**1**
Табигатжнең һәр сулышы
Аллага багышланган.
Аңа гына төнге күктә
Йолдызлар елмаялар.

**2**
Кояш та беренче нурын
Аллага багышлаган.
Тау астында көмеш чишмә
Догасында чылтырый.

**3**
Урман шаулый догасында,
Чәчәкләр баш ияләр.
Аны мактап кошлар сайрый,
Җилләр җырлап исәләр.

**4**
Изге Атам, бөек Аллам,
Миндә Синең иҗатың,
Барлыгыңа бу дөньяда
Мин дә шатланып җырлыйм!

## Йөрәгемә керде Гайсәм

**1**

Йөрәгемә кердең Гайсәм
Мин шатланам, куанам.
Билэп алдың күңелемне
Сине уйлап юанам.
Бөек Аллам- Изге Гайсәм,-
Куанычым Син минем,
Бөек Аллам, Изге Гайсәм,-
Ышанычым – Син минем.

**2**

Син һәр вакыт булчы минем
Йөрәгемнең түрендә.
Синең мактаулы исемең
Мәнге булсын телемдә.
Изге Гайсәм, минем Гайсәм,-
Таянычым Син минем.
Изге Гайсәм, минем Гайсәм-
Ышанычым Син минем.

**3**

Рәхмәт Сиңа, Бөек Гайсәм,
Арчыладың гөнаһтан.
Минем өчен корбан булып
Коткардың Син газаптан.
Изге Гайсәм, минем Гайсәм,-
Коткаручым Син минем,
Изге Гайсәм, минем Гайсәм,
Таянычым Син минем.

**4**

Мәхрүм итмә безне Аллам,
Тиңсез мәхәбәтеңнен.
Калдырма безне беркайчан
Чиксез Бәрәкәтеңнән.
Син бит минем, Изге Гайсәм,-
Куанычым Син минем,
Син бит минем Изге Гайсәм
Ышанычым Син минем.

## Данлагыз сез Алланы

**1**

Данлагыз сез , данлагыз Алланы
Һәр яңа көн жирдә туганда.
Данлагыз сез авыр минутларда,
Һәм шатлыктан күңел тулганда.

***<u>Кушымта</u>*:**

**Данлагыз сез ихлас күңелдән**
**Йөрәк түреннән.**
**Данлагыз сез һәр көн Аны**
**Җыр белән.**

**2**

Данлагыз сез, данлагыз Алланы,
Һәр мизгел сез Аны данлагыз!
Данлагыз сез, Аның Мәхәббәтен,
Аның бөеклеген данлагыз!

**3**

Данлагыз сез, данлагыз Алланы
Данлагыз сез гомер буена.
Тик Ул гына безне яратучы,
Безне коткаручы Ул гына.

## Аллага шөкер!

**1**

Бер максатсыз гел заяга
Узмасын гөмер.
Исәнбез без, яшибез без,
Аллага шөкер!

**2**

Кайгы бетәр, шатлык белән
Бу гөмер узар.
Без бит беогә- шунсы шатлык,
Аллага шөкер!

**3**

Алла бирсә, җырларбыз без
Узганчы гөмер.
Исәнбез без, җырлыйбыз без,
Аллага шөкер!

**4**

Мәңге Сине без данларбыз,
Рәхәтләр булыр
Без бит Гайсә Синең белән,
Аллага шөкер!

## Ходай, исәнлек бир Син безгә

**1**

Кешегә гомерләр бирелгән,

Мең түгел, бары тик бер генә,
Бик азга килгәнбез бу җиргә,
Дөрес юл күрсәт Син гел генә.
Син безне ташлама мәңгегә, мәңгегә
Бу ачы язмышлар кулына.
Ташлама беркайчан, беркайда, беркемгә
И Ходаем мәхәббәт бир безгә. /2

**2**

Тиз үтә бу тормыш юллары,
Ә алда- мәңгелек дөньясы,
Гонаһлар кылмыйк без, туганнар,
Бер Ходай каршына барасы.
Син безне ташлама мәңгегә, мәңгегә
Ышаныч һәм иман бир безгә,
Кичер Син без кылган күп яман эшләрне,
И Ходаем, тәүфик бир Син безгә! /2

## Гайсә Мәсих иң бөек Исем

Безнә көткаручы, Безнең Ходай!
Аллада уе, Алла безнең белән,
Азат итүче мәңге яши

## Гайсә белән мин барырга булдым

**1**

Гайсә белән мин барырга булдым/3
Мин борылмам шушы юлдан.

**2**

Дөнья артымнан, Алла алдымнан/3
Мин борылмам шушы юлдан.

**3**

Үзем калсам да Гайсә белән мин/3
Мин борылмам шушы юлдан.

## Өйрәт мине Ходаем.

**1**
Й, Ходаем, Үзең өрәт мине
Чын күңелдән дога кылырга
Буйсындырып горур йөрәгемне
Синең алда ихлас булырга. /2
**2**
Өйрәт мине Синең белән генә
Бәхәтле һәм көчле булырга.
Шатлык һәм кайгылар килгәндә дә,
Тик Синең артыңнан барырга./2
**3**
Өйрәт мине тирән сөю белән
Яратырга якыннарымны,
Чистартырга мине гөнаһлардан
Кызганмадың изге каныңны. /2

## Алла Ул мәхәббәт

**1**
Алла Ул мәхәббәт,
Нинди зур бәхет
Алла мәхәббәт Ул,
Безне ярата.
***Кушымта:***
**Жарсы да шатлансын,**
**Жырласын, данласын;**
**Алла мәхәббәт!**
**Алла мәхәббәт!**
**2**
Алла Ул мәхәббәт,
Жибердә Үзен Улын,
Алла мәхәббәт Ул
Безне котркарды.
**3**
Алла Ул мәхәббәт,
Безне азат итте,
Алла мәхәббәт Ул
Безне азат итте.

## Инде күп еллар үтте

**1**
Инде күп еллар үтте
Бу гаҗәп хәлләрдән соң.
Тик Синең исемең Гайсә
Олылана телләрдә
***Кушымта:***
**Рәхимле Бөек Алла!**
**Бу дөньяны яратып,**
**Җибәргәнсең Улыңны**
**Үлемнән коткарырга. /2**
**2**
Һачтагы газапларың,
Җафаланып үлүең,
Һәм Синең соңгы доган
Үтеп керде йөрәккә.
***Кушымта:***
**“ Кичер аларны, Атам,**
**Явызлыклары өчен.**
**Чөнки алар белмиләр**
**Нәрсә эшләгәннәрен. /2**
**3**
Тәмугъ үлем көчләре
Сиңа каршы тордылар
Тик Син барын да җиңдең,
Үлүдән Син терелдең.
***Кушымта:***
**Кодрәтле Гайсә Мәсих,**
**Аллага Син юл булдың.**
**Һәркем Сиңа ышанган**
**Мәңге тормышлы була. /2**
**4**
Бцек Мактаулы исем
Балкый минем йөрәктә.
Мәңге булчы телемдә
Йөрәгемнең түрендә.
***Кушымта:***
**Ходаем Гайсә Мәсих-**
**Мәңгелек Аллам минем.**
**Мактан барча телләрдә**
**Бар халыкларда данлан. /2**

## Алла Патша

Алла Патша безнең,
Патша безнеэ Ата
Ул безне бик ярата,
Һәм бәхетле итә.

Гайсә көчле көрәште,
Ул һаман җинеп бара.
Гайсә Ул- җинуче.
Һәм көчле Гайсә кебек
Җиңәрбез дә һәрвакыт
Җиңәрбез, Гайсә белән җиңәрбез.

## Синең белән сөйләшәсем килә

**1**
Синең белән сөйләшәсем килә,
Син якын һәм тугры Дустым.
Күк йөзеннән, Аллам, миңа кара
Ярсып тибә минем йөрәгем.

**2**
Синең белән сөйләшәсем килә,
Йөрәгемдә авыр кайгы бар
Юат мине, ярдәм ит Аллам
Сабырлык бир, көч һәм шатлыклар.

**3**
Синең белән сөйләшәсем килә
Дусларым күп, алар еракта.
Тик Син генә минем таянычым
Көч Бирүче, Яклаучым минем.